
**Нургатин Закир абый (1931-2015) истәлекләре белән улы Нургатин И.З. таныштырды.**



... “Балачагым авыр сугыш елларына туры килде. Авылдагы бөтен авыр эш безнең җилкәгә төште. Авыр булса да түздек, сынмадык-сыгылмадык. Мәктәптә яхшы укырга да, колхоз, җәмәгать эшенә дә өлгердек.
Пионерга 3нче класста укыганда алдылар. Барысы алдында тантаналы ант биреп, без пионерлар сафына бастык. һәрчак әлеге антка тугры, пионер исеменә лаек булырга тырыштык.Без класста 32 бала идек.Мин Ахметзянов Марс, Галиева Рахилә, Насыров Марс, Ислямов Минхаж, Галиева Сагидәләр белән бергә укыдым.
Безнең мәктәптә укыткан укытучылардан истә калганнары :

-Ильина Евдокия(Бахта)
-Мөнирә апа( Мораса)
-Вәсимә (Адәм Суы)
-Сәлимгәрәева Әлфия(Адәм суы)
-Ермолаева Анна (Кр. Баран)
-Журавлева Анна(Бахта)
-Кольцов

Көл җыю, ялгызы яшәгән әби-бабайларга ярдәм итү, колхоз ындырында эшләү, теге яки бу бәйрәм уңаеннан концерт кую — бу җәмәгать эшләренең берсеннән дә читтә калмадык. Фронтка посылкалар җибәрү дә хәтердә. Туган илебез азатлыгы хакына көрәшкән солдатларга кош теледәй сәламебезне, әниләребез бәйләгән оекбаш-бияләйләрне җибәрү безнең өчен олы горурлык булды. Менә шундый булды ул безнең балачак

Урманасты Шынталы